# КАРАР

**04 апрель, 2024 ел** **№1**

Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 11 ноябрендәге 1 номерлы Лельвиж авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 04 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 80 яшькә җиткән затлар һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары;
- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары

2100 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру
- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту;
- трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау
- урам яктыртуны карап тоту (Лельвиж авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау)
- Лельвиж авылы чишмәләрен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре»
- мотопомпа сатып алу
- Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү
- спорт инвентаре сатып алу
- Авыл көне бәйрәме үткәрү?

2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау** *(материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре); (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; (Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү)*

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** *(Лельвиж авылы чишмәләрен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары, эшләү, килешү буенча түләү)*

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** *(Лельвиж авылында урам-юл челтәрен карап тоту,ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка эш төрләре) (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** *(Лельвиж авылы территориясен төзекләндерү, җәен печәнен чабу һәм кышын кардан арындыру, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*
*(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*
*(трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);*

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** *(мотопомпа сатып алу)*

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 392 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **196** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 193 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар),
- 80 яшькә җиткән затлар һәм аннан да өлкәнрәкләр,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокла хәрби хезмәткә чакырылган затлар,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары,
- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары
500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру
- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту;
- трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау
- урам яктыртуны карап тоту (Лельвиж авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау)
- Лельвиж авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- мотопомпа сатып алу
- Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү
- спорт инвентаре сатып алу
- Авыл көне бәйрәме үткәрү?

2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау** *(материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре); (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан*

*скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү)*

**- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** *(Лельвиж авылы чишмәләрен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары, эшләү, килешү буенча түләү)*

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** *(Лельвиж авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка эш төрләре) (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** *(Лельвиж авылы территориясен төзекләндерү, җәен печәнен чабу һәм кышын кардан арындыру, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*
*(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*
*(трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);*

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (*мотопомпа сатып алу)*

«РИЗА» «КАРШЫ» кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева